Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Чыты авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Чыты авыл җирлеге Башлыгы
КАРАРЫ

3 октябрь, 2024 ел № 2

Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге уставының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Чыты авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2019 елның 08 ноябрендәге 153 номерлы Чыты авыл җирлеге Советы карары (2021 елның 14 декабрендәге 35 номерлы карары белән расланган үзгәрешләр белән) нигезендә карар бирәм:

1. Чыты авылы җирлегендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

1.2. Чыты авылында. Гражданнар җыенын ике этапта уздырырга:

- гражданнар җыенының беренче этабы 2024 елның 15 октябрендә 10 сәгать 00 минутта Совет ур., 126А й. адресы буенча урнашкан авыл җирлеге административ бинасы янында. Җыенда катнашучылар исемлегенә Чулпан, Болын, Газинур, Зур, Күпер урамнары буенча теркәлгән халыкны кертергә;

- гражданнар җыенының икенче этабы 2024 елның 15 октябрендә 13 сәгать 00 минутта Кооператив ур., 85 й. адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында. Җыенда катнашучылар исемлегенә Колхоз, Кооператив, Вахитов Мәктәп, Үзәк, Совет урамнары буенча теркәлгән халыкны кертергә;

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез, 2025 елда Чыты торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын, 90 яшьтән өлкәнрәк гражданнарны, студентларны бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, 1750 сум күләмендә үзара салым кертүгә, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- традицион җирләү урыннарын төзекләндерү;

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.2. Иске Йорт авылында. Гражданнар җыенынын 2024 елның 16 октябрендә 10 сәгать 00 минутта Кооператив ур., 34 й. адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез, 2025 елда Иске Йорт торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын, 90 яшьтән өлкәнрәк гражданнарны, студентларны бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, 1750 сум күләмендә үзара салым кертүгә, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- традицион җирләү урыннарын төзекләндерү;

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чыты авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

Питрәч муниципаль районы
Чыты авыл җирлеге башлыгы С.Ә. Фәйзрахманов